**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы төзү турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы төзү турында» 2009 елның 30 декабрендәге ПУ-703 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 3 ноябрендәге ПУ-717 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 ноябрендәге ПУ-1083 номерлы, 2014 елның 1 ноябрендәге ПУ-1015 номерлы, 2016 елның 23 гыйнварындагы ПУ-27 номерлы, 2016 елның 7 декабрендәге ПУ-1085 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 2 февралендәге ПУ-132 номерлы, 2018 елның 6 июлендәге ПУ-473 номерлы, 2019 елның 8 февралендәге ПУ-88 номерлы һәм 2020 елның 31 гыйнварындагы ПУ-50 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Милләттәшләр эшләре буенча координация советы (алга таба – Совет) составында:

Совет составыннан Р.Т. Борһановны, Н.М. Владимировны, Р.З. Закировны, Җ.Ш. Сөләймановны чыгарырга;

Совет составына кертергә:

Һадиуллин Илсур Гәрәй улын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Шаһиәхмәтов Мидхәт Рәфкать улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министрын;

Шакиров Данис Фәнис улын – Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесен (килешү буенча);

Яковлев Константин Геннадиевичны – Татарстан халыклары ассамблеясе советы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан халыклары ассамблеясе советы рәисе урынбасарын (килешү буенча);

Совет әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ә.С. Гобәйдуллинның – «Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы» ассоциациясе рәисе (килешү буенча)»;

Р.С. Хәкимовның – «Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе вице-президенты, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты фәнни җитәкчесе»;

б) Совет турында нигезләмәдә:

5 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«аерым мәсьәләләр буенча эш төркемнәре һәм эксперт төркемнәре оештыра.»;

6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Татарстан Республикасы Президенты Аппараты ГОМУМИ БҮЛЕК Аппарат Президента Республики Татарстан ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2021 ел, 01 февраль
№ ПУ-70